Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШТУГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Иштуган т.ю.т.б., Үзәк урамы, 11 йорт
тел. 8 (84362) 4-20-37

Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
П.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, д. 11
тел. 8 (84362) 4-20-37

isht.sab@tatar.ru

2019 нчы елның 02 нче апреле № 12

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт
ителми торган биналарга, корылмаларга,
бүлмәләргә якын урыннарның схемасын раслау турында

1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 нче номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафыннан тэртипкә салу турында» Федераль законның 16 нчы матдәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» карары, ТР Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 нче мартында кабул ителгән 7 нче номерлы “Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннар турында” карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган түбәндәге территорияләрнең схемаларын расларга:

1.1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган “Каенкай” балалар бакчасы” МБМБУга якын булган территорияләренең схемасын;

1.2. “Саба үзәкләшкән авыл клублары системасының” 7 нче номерлы филиалына (Иштуган авыл клубына), Иштуган фельдшер-акушерлык пунктына якын булган территорияләрнең схемасын;

1.3. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган урта гомуми белем бирү мәктәбе” МББУга якын булган территорияләрнең схемасын.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 29 нчы ноябрендә кабул ителгән 19 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннарның схемасын раслау турында» карарын үз

көчен югалткан дип танырга.


3. Әлеге Карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://saby.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов


Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 нчы елның 02 апрелендә кабул ителгән
12 нче номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган “Каенкай” балалар бакчасы” МБМБУга якын булган территорияләренең схемасы



Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 нчы елның 02 апрелендә кабул ителгән
12 нче номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган
"Саба үзәкләшкән авыл клублары системасының" 7 нче номерлы филиалына
(Иштуган авыл клубына), Иштуган фельдшер-акушерлык пунктына якын булган
территорияләрнең схемасы



Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 нчы елның 02 апрелендә кабул ителгән
12 нче номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган урта гомуми белем бирү мәктәбе” МББУга якын булган территорияләрнең схемасы

